МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.11.2019 г.Казань № 1043

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 9 декабрендә 5978 номеры белән теркәлде

2020 елда вакытлыча эшкә урнаштыру чорына балигъ булмаган һәм эшсез гражданнарга матди булышлык күрсәтү күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2020 елга түбәндәгечә матди булышлык күрсәтү күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең 1,5 тапкыр минималь күләменә тигез суммада;

түләүле иҗтимагый эшләрдә катнашучы эшсез гражданнарга, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез суммада;

эш эзләп табуда кыенлыклар кичерүче эшсез гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына, аена бер кешенә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез суммада;

урта һөнәри белемгә ия булып һәм тәүге мәртәбә эш эзләүче, 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез суммада;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлап чыгучылар исәбендәге эшсез гражданнарга аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына, аена бер кешегә, эшсезлек буенча пособиенең минималь күләменең 1,5 тапкырга тигез суммада.

2. Әлеге боерык 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова